ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 15 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 30 июнендәге 48-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 54 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда «Федераль закон» сүзләреннән соң «(алга таба – Федераль закон)» сүзләрен өстәргә;

2) 2 статьяда «Хәйрия эшчәнлеге һәм ихтыярыйлык (волонтерлык) турында» 1995 елның 11 августындагы 135-ФЗ номерлы» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 3 статьяда:
а) 3 өлештә «үзара эшләве тәртибен» сүзләрен «үзара эшләвенең Федераль законның $17^3$ статьясындагы 1 пунктының 2 пунктчасында каралган эшчәнлек төрләренең үзенчәлеген һәм Федераль законның $17^3$ статьясындагы 1 пунктының 1 пунктчасы нигезендә расланган гомуми таләпләрне исәпкә ала торган тәртипләрен» сүзләренә алмаштырырга;
б) 4 өлештә:
1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1) ихтыярый ярдәм итү (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашучыларга, шул исәптән аларның дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр, башка оешмалар белән үзара эшләвендә, ихтыярый ярдәм итү (волонтерлык) эшчәнлегендә

катнашучыларга оештыру, мәгълүмати, методик һәм бүтән төрле ярдәм күрсәтүне тәэмин итүче социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга, дәүләт учреждениеләренә һәм муниципаль учреждениеләргә Федераль законда һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, шулай ук Татарстан Республикасы законнарында һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында каралган рәвешләрдә ярдәм күрсәтү;»;

түбәндәге эчтәлекле $2^1$ – $2^3$ пунктлар өстәргә:

«$2^1$) Татарстан Республикасы территориясендә ихтыярыйлык (волонтерлык) ресурс үзәге функцияләрен гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешманы Федераль законның $17^2$ статьясындагы 2 пункты нигезендә расланган тәртиптә билгеләү;

$2^2$) ихтыярый ярдәм итү (волонтерлык) эшчәнлегенең тотрыклы эшләвен тәэмин итү, аны гамәлгә ашыру һәм аңа ярдәм итү инфраструктурасын булдыру максатларында, финанс, матди һәм кадрлар белән тәэмин итүне дә кертеп, шулай ук Федераль законның $17^4$ статьясында каралган башка рәвешләрдә ихтыярыйлык (волонтерлык) ресурс үзәгенә ярдәм күрсәтү;

$2^3$) ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашучыларга, Федераль законның $17^4$ статьясындагы 2 пунктында каралган рәвешләрне исәпкә алып, ярдәм итү чаралары исемлеген билгеләү;»;

в) 5 өлешкә түбәндәге эчтәлекле $5^1$ пункт өстәргә:

«$5^1$) ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру максатларында ихтыярыйлыкны (волонтерлыкны) үстерү өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасына кертү өчен белешмәләр тапшыру;»;

4) 4 статьяда:

а) 2 пунктта «үзара эшләве тәртибен» сүзләрен «үзара эшләвенең Федераль законның $17^3$ статьясындагы 1 пунктының 2 пунктчасында каралган эшчәнлек төрләренең үзенчәлеген һәм Федераль законның $17^3$ статьясындагы 1 пунктының 1 пунктчасы нигезендә расланган гомуми таләпләрне исәпкә ала торган тәртипләрен» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) ихтыярый ярдәм итү (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашучыларга, шул исәптән аларның дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр, башка оешмалар белән үзара эшләвендә, ихтыярый ярдәм итү (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашучыларга оештыру, мәгълүмати, методик һәм бүтән төрле ярдәм күрсәтүне тәэмин итүче социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга, дәүләт учреждениеләренә һәм муниципаль учреждениеләргә Федераль законда һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, шулай ук Татарстан Республикасы законнарында һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында, муниципаль норматив хокукый актларда каралган рәвешләрдә ярдәм күрсәтү;»;

в) түбәндәге эчтәлекле 4 – 6 пунктлар өстәргә:

«4) ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендәге координацион һәм киңәшмә органнарын булдыру;

5) ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру максатларында ихтыярыйлыкны (волонтерлыкны) үстерү өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасына кертү өчен белешмәләр тапшыру;

6) ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашучыларга, Федераль законның $17^4$ статьясындагы 2 пунктында каралган рәвешләрне исәпкә алып, ярдәм итү чаралары исемлеген билгеләү.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2024 ел, 26 февраль
№ 2-ТРЗ